СОВЕТ САЛАУССКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СЛАВЫЧ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ
«16» июль 2024 ел

КАРАР
№ 104

**Җирле салым суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пунктына туры китереп, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Законы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Салавыч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. 2024 елның 1 гыйнварына җирле салымнар суммасының аерым салым түләүчеләр өчен исәпләнүче, түбәндәге нигезләр буенча түләү һәм (яисә) түләтү мөмкин булмаган суммалар өлешендә түбәндәгеләр түләтүгә өметсез дип таныла:

1) варислар мираска хокуктан баш тарткан, варислар булмаган яисә мирас ачылган көннән бер ел дәвамында мирас кабул ителмәгән очракта, үлгән яисә вафат булган дип саналган физик затларның бурычы булу;

2) оешмаларда яисә шәхси эшмәкәрләрдә 2024 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнарбуенча исәпләнә торган бурыч булу;

3) Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң физик затларның 500 сумнан артмаган суммада бурычы булу.

2. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре булуын раслаучы документларга түбәндәгеләр керә:

1) әлеге карарның 1 пунктының 1 бүлегендә күрсәтелгән нигезләр булганда:

а) салым органыннан физик затның яшәү урыны буенча бурыч суммасы турында белешмә;

б) салым органнарында үлем белән бәйле очракта физик затны исәптән төшерү турында белешмәләр;

в) салым органыннан мираска хокук билгеләүче таныклык бирү хакында белешмәләр булмау турында белешмә;

2) әлеге карарның 1 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр булганда:

а) оешма, шәхси эшмәкәр, шәхси эшкуар статусын югалткан физик зат исәбе буенча бурыч суммасы турында салым органы белешмәсе;

б) салымны юкка чыгару өчен нигез булган норматив хокукый акт турында белешмәләр (атамасы, дата, номеры);

3) әлеге карарның 1 пунктының 3 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда - салым органыннан суммасы 500 сумнан артмаган бурыч барлыгы турында белешмә.

3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлеге Советының 2023 елның «28» апрелендә "Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында" 76 нчы номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi. tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Салавыч авыл җирлеге Советы башлыгы,
Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Салавыч авыл җирлеге Советы рәисе

Р.К.Латипов